СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станции Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

Кооперативная ур, 5. Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-60, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**23 октябрь, 2024 ел** **№ 455**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы «Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» муниципаль казна учреждениесе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның 06 декабрендәге 341 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Норматив хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү максатында, Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәте хаты нигезендә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының 2019 елның 06 декабрендәге 341 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы «Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» муниципаль казна учреждениесе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 4 бүлекнең 4.1 пунктын түбәндәге эчтәлекле 4.1.8 пунктча белән тулыландырырга:

«4.1.8. Үз функцияләрен тәэмин итү өчен, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системаларыннан, шулай ук пространство белешмәләренең илкүләм системасы эшчәнлеген тәэмин итә торган федераль дәүләт географик мәгълүмат системасыннан файдаланырга.».

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча игълан итәргә һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Совет рәисе,
муниципаль район Башлыгы Р.Ф. Хисамөтдинов